# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«20» 11 2019 ел Яр Чаллы № 5114

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 сентябрендәге «Тукай муниципаль районы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары хакында» 4049 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 сентябрендәге «Тукай муниципаль районы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары хакында» 4049 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары хакында (1 кушымта) нигезләмәдә:

V бүлек 2 пунктның сигезенче абзацында «300» саннарын «550» саннарына алыштырырга;

VI бүлек 15 пунктта, 15.11 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәнең (2 кушымта) V бүлек 12 пунктында, 12.11 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәнең (3 кушымта) VI бүлек 8 пунктында, 8.11 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы А.Х. Мөхәммәтҗановага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов